ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.09.2024
1484

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 ноябрендәге 1677 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 8 июлендәге 173- ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 ноябрендәге 1677 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 3.3.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен, мөрәҗәгать итүче булып торучы балигъ булмаганның законлы вәкиле алганда, балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләрен алу хокукын гамәлгә ашыру мөрәҗәгать итүче булмаган балигъ булмаганның законлы вәкиле тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин. Бу очракта балигъ булмаганның законлы вәкиле булган мөрәҗәгать итүче, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаганның балигъ булмаганга карата тиешле

хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алуга вәкаләтле башка законлы вәкилнең фамилиясен, исемен, әтисенең исемен (булган очракта) күрсәтә, шәхесен таныклаучы документ турында белешмәләрне күрсәтә.

Балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләре, әгәр мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең сорала торган нәтиҗәләрен шәхсән үзе алырга теләк белдергән булса, балигъ булмаганның башка законлы вәкиленә күрсәтелми.».

1.2. Регламентның 2.3. пунктын түбәндәге эчтәлекле 2.3.4. пунктчасы белән тулыландырырга:

«2.3.4. Мөрәҗәгать итүче булмаган балигъ булмаганның законлы вәкиле тарафыннан балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алу хокукын гамәлгә ашыру.

Балигъ булмаганга карата дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче балигъ булмаганның законлы вәкиле алганда, балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләрен алу хокукын гамәлгә ашыру мөрәҗәгать итүче булмаган балигъ булмаганның законлы вәкиле тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин. Бу очракта балигъ булмаганның законлы вәкиле булган мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаганның балигъ булмаганга карата тиешле хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алуга вәкаләтле башка законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документ турында белешмәләрне күрсәтә.

Балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләре, әгәр мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең сорала торган нәтиҗәләрен шәхсән үзе алырга теләк белдергән булса, балигъ булмаганның башка законлы вәкиленә күрсәтелми.»;

1.1. Регламентның 2.8.2. пунктын түбәндәге эчтәлекле 13 пунктча белән тулыландырырга:

«13) мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәлдә булган вәкилнең муниципаль хезмәт алуга тиешле вәкаләтләре булмау.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.Д. Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын
вакытлыча башкаручы А.А. Томилин